**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«10» 02 2020 ел Яр Чаллы № 241

Тукай муниципаль районының су биологик ресурсларын саклау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем составын раслау турында

Татарстан Республикасында су биологик ресурсларын саклау мәсьәләсе буенча 2016 елның 16 декабрендәге ВШ-12-390 номерлы киңәшмә беркетмәсенең 7 пунктын үтәү йөзеннән,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районының су биологик ресурсларын саклау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркемен төзергә һәм составын расларга.
2. Башкарма комитетның 2019 елның 28 мартындагы 1155 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм районның рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 10.02 2020 елның 241 номерлы карарына кушымта

Тукай муниципаль районының су биологик ресурсларын саклау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем составы

Авзалов Ленар Гаяз улы – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе, эшче төркем рәисе;

Хәбибуллин Айрат Рафак улы – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары, эшче төркем рәисе урынбасары;

Миннеханова Гүзәл Ринат кызы – Башкарма комитетның баш белгече, административ комиссиянең җаваплы секретаре, комиссия секретаре.

Эшче төркем әгъзалары:

Елисеев Владимир Александрович – Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге башлыгы;

Фәрдиев Илнур Марат улы – Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге, икътисадый иминлек һәм коррупциягә каршы тору баш идарәсе бүлегенең өлкән оператив вәкаләтле хезмәткәре, полиция майоры;

Хафизов Эльмир Әхтәм улы – Татарстан Республикасы буенча су биологик ресурсларына дәүләт контроле, күзәтчелеге һәм саклау бүлеге өлкән дәүләт инспекторы;

Хәйбуллин Ленар Радик улы – «Тукай районы ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы;

Юсупова Резидә Мәхмүт кызы – «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы җитәкчесе, «Якты юл» («Светлый путь») газетасы баш редакторы;

Яцук Павел Борисович – ТР Хайваннар дөньясын саклау идарәсенең район (районара) бүлеге башлыгы.